ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны педагогик эшчәнлеккә җәлеп итү өчен, шулай ук педагогик хезмәткәрләргә социаль ярдәм итү максатларында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән өстәмә дәүләт ярдәме чаралары һәм социаль гарантияләр билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 12 апрель
№ 14-ТРЗ